Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль район Советының сигезенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

3 март, 2021 ел № 50

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законга, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына туры китерү максатларында **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2014 елның 21 ноябрендәге 206 номерлы карары (2020 елның 30 июлендәге 281 номерлы үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 12 өлешнең 5 пунктын төшереп калдырырга.
- 12 өлешнең 6, 7, 8, 9 пунктларын, 12 өлешнең 5, 6, 7, 8 пунктларын дип санарга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы Советының җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлеге, законлылык, хокук тәртибе һәм регламенты буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов